**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Учаллинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Үчәлле авылы җирлек БАШЛЫГЫ**

ул. Советская, д. 51 , село Учалле,
Азнакаевского муниципального
района, 423317 Тел. (факс) (85592)
36-8-32
E-mail:Uchal.Azn@tatar.ru

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
E-mail:Uchal.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 август 2017 ел №4

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Үчәлле авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль берәмлегенең «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча Үчәлле авыл җирлегендә яшәүчеләрнең фикерен һәм мәнфәгатьләрен ачыклау һәм исәпкә алу максатларында, Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, карар бирәм:

1.Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларны билгеләргә:

1.1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы Якты Күл авылы, Якты Күл ур., 15, .адресы буенча урнашкан 921 кв. м мәйданлы барлыкка килә торган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә. махсуслаштырылган билгеләнештәге клублар - индивидуаль торак төзелеше зонасында клуб төзү өчен (Ж1).

2. Билгеләләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы тарафыннан Үчәлле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә;

- үткәрү вакыты – 2017 елның 12 сентябрендә 14.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны-Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы, адресы: Үчәлле авылы, Совет ур., 51

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кертелергә мөмкин: Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитеты (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр).

3. Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссияләре Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге:

- җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында 2017 елның 12 сентябренә кадәр рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртүгә рөхсәт сорала торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең хокук ияләренә хәбәрләр җибәрергә;

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны

билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Г.М. Төхфәтуллина